**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2025 **Чирмешән авылы** **№ 283**

2026-2028 елларда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында» 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2026-2028 елларда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2026-2028 елларда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә

капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
01.10.2025 № 283

2026-2028 елларда
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның
кыска сроклы планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

2026-2028 елларда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның әлеге кыска сроклы планы (алга таба – Кыска сроклы план, Региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның региональ программасын раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтү һәм (яисә) эш төрләрен төгәлләштерү, дәүләт ярдәме, капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнде.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары булып тора:

– Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын арттыру;

– гражданнар яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру;

– күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска сроклы планның төп бурычлары булып тора:

– халык белән актив агитация-аңлату эше алып бару;

– кыска вакытлы план үтәүчеләрне сайлап алуның үтә күренмәле һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;

озакка чыдам материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләр кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрдән һәм комплекслылыктан файдалану.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2028 еллар.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 4 581,7 кв. метр булган 4 күпфатирлы йортта 144 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге кыска сроклы планны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре тулаем Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы буенча кыска сроклы планга 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

## III. 2026-2028 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләмнәре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | 2026 | 2027 | 2028 |
| Түбәне ремонтлау | кв. м | 1 040,00 | 140,00 | 400,00 | 500,00 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. м | 350,00 | 350,00 | - | - |
| Фасадны ремонтлау | кв. м | 630,00 | 250,00 | 380,00 | - |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән: | | | | | |
| электр белән тәэмин итү | пог. м | 100,00 | 100,00 | - | - |
| салкын су белән тәэмин итү | пог. м | 160,00 | - | - | 160,00 |

Кыска сроклы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге кыска сроклы планга 3 нче кушымтада китерелгән.

## IV. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты, торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба – ТСЖ, ТК, ТТК) яисә башка

махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары йә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре акчалары тора.

Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме 31.671.236, 52 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджетыннан – 24 000 000,00 мең сум;
- Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан – 1 848 000,00 мең сум;
- күпфатирлы йортта торак милекчеләре - 5 823 236,52 мең сум.

**2026-2028 елларда**
**күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга**
**финанс чаралары күләме**

| Хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Сумма, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | 2026 | 2027 | 2028 |
| Түбәне ремонтлау | 18 334 171,95 | 2 273 644,17 | 6 654 792,94 | 9 405 734,84 |
| Фасадны ремонтлау | 8 624 403,97 | 5 064736,70 | 3 559 667,27 | - |
| Подъездларны ремонтлау | 1 843 517,00 | 1 843 517,00 | - | - |
| Йорт эчендәге инженер системалары | 1 880 887,00 | 930 127,00 | - | 950 760,00 |
| Проект документациясен эшләү | 386 504,60 | 244 469,97 | 142 034,63 | - |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 601 752,00 | 200 584,00 | 200 584,00 | 200 584,00 |
| **Барлыгы** | **31 671 236,52** | **10 557 078,84** | **10 557 078,84** | **10 557 078,84** |

Капиталь ремонт үткәрү бәясе күрсәтелгән күпфатирлы йортлар исемлеге кыска сроклы планга 4 нче кушымтада китерелгән.

## V. Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе 2026-2028 елларга күпфатирлы йортлардагы биналарның гомуми мәйданының 1 кв.метрына исәпләгәндә 14 мең сум тәшкил итә.

Шул ук вакытта әлеге кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүнең (эшнең) иң чик бәясе күләме эш төрләре буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба - Министрлык) боерыгы белән раслана.

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясеннән артып китү, шулай ук Кыска сроклы планда каралмаган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өчен түләү күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән артыграк күләмендә капиталь ремонтка кертем рәвешендә түләнә торган акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясеннән артып киткән өчен кыска сроклы планны гамәлгә ашыруга каралган җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләү рөхсәт ителә.

## VI. Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска сроклы планны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты, Торак милекчеләре ширкәте, Торак кооперативы, Торак-төзелеш кооперативы, идарәче оешма (алга таба - Идарәче оешма), биналар милекчеләре, подряд оешмалары (алга таба - Кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты:**

– күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, өч елга төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планнарын төзи һәм Министрлыкка җибәрә;

– Министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм муниципаль берәмлекнең финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәвен раслый торган башка документларны тапшыра;

– капиталь ремонт эшләрен торак законнары нигезендә кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә финанслауга җирле бюджет акчаларын күчерә;

– региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләрнең техник заказчысы функцияләрен башкара;

– башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын килештерә, моңа күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау чыгымнарының расланган сметасында каралмаган акчалардан файдалану очраклары керми, шулай ук ул арткан очракта;

– күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан файдаланылуын тикшереп тора;

– тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләрне) гамәлгә ашыру максатларында белешмәләр базасын төзи һәм актуаль хәлдә тота;

– Министрлыкка һәм кыска сроклы планны башка башкаручыларга дәүләт корпорациясенә - торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фондына хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр тапшыра.

**Торак милекчеләре ширкәте, Торак-төзелеш кооперативы, Торак кооперативы, Идарәче оешма:**

– тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;

– проект документациясен килештерүне тәэмин итәләр;

– урыннар милекчеләренә капиталь ремонтны башлау срогы, кирәкле исемлек һәм хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр кертәләр;

– күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышлары оештыралар;

– капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;

– күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны тикшереп торалар, шулай ук капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә тикшерү актларына һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларына имза салу хокукы белән катнашалар;

– күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча дефектлы ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документацияне күпфатирлы йортны һәм аңа керә торган инженер системаларын авариясез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия срогыннан ким булмаган килеш саклыйлар;

– төбәк операторы белән шартнамәләр (килешүләр) төзи, алар нигезендә Торак милекчеләре ширкәте, Торак-төзелеш кооперативы, Торак кооперативы, Идарәче оешма түләү документларын төзи һәм ай саен исәпләүне, төбәк операторы счетына капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләрнең түләүләрен, шулай ук капиталь ремонт өчен кертемнәр һәм пеня түләү буенча бурычларны түләтү чараларын тәэмин итә.

**Биналарның милекчеләре:**

– тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;

– күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны тикшереп торуда, шулай ук тикшерү актларына һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларына имза салу хокукы белән аларны файдалануга кабул итүдә катнашалар.

**Подряд оешмалары:**

– күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен кыска сроклы план һәм подряд шартнамәсендә билгеләнгән срокларда башкаруны тәэмин итәләр;

– башкарылган эшләрнең актларын КС-2, КС-3 формалары буенча төзиләр;

– күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

– күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

– объектны эксплуатациягә кертүне тәэмин итәләр;

– подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

**Техник заказчылар:**

- проект документациясен, шул исәптән сметаларны әзерләү һәм раслауны гамәлгә ашыралар;
- күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;
- башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләрнең актларын килештерәләр;
- объектны кабул итүдә катнашалар, капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе төзиләр, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү комиссиясе актларын килештерәләр;
- күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;
- проект оешмасыннан проект документациясен кабул итәләр;
- күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куелганнан соң 10 көн эчендә шушы күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән проект-смета документациясенең, хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәләрнең һәм (яисә) капиталь ремонт башкару турында шартнамәләрнең күчермәләре) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар, финанс документларыннан тыш;
- техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен башкара.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VII. Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру тәртибе

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

**Приложение № 2**
**к Краткосрочному плану реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Черемшанского муниципального района Республики Татарстан, в 2026 – 2028 годах**

**Планируемые показатели**
**выполнения Краткосрочного плана реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Черемшанского муниципального района Республики Татарстан,**
**в 2026 – 2028 годах**

| № п/п | Наименование муниципального образования | Общая площадь многоквартирных домов, кв.метров | Количество жителей, зарегистрированных в многоквартирных домах на дату утверждения Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан | Количество многоквартирных домов, единиц | | | | | Стоимость капитального ремонта, рублей | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | всего | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | всего |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 2026 год | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Черемшанский муниципальный район | 813,00 | 37 | | | | 1 | 1 | | | | 10 557 078,84 | 10 557 078,84 |
| 2027 год | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Черемшанский муниципальный район | 994,60 | 43 | | | | 1 | 1 | | | | 10 557 078,84 | 10 557 078,84 |
| 2028 год | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Черемшанский муниципальный район | 2 774,10 | 64 | | | | 2 | 2 | | | | 10 557 078,84 | 10 557 078,84 |
| | ИТОГО | 4 581,70 | 144 | | | | 4 | 4 | | | | 31 671 236,32 | 31 671 236,52 |

**Приложение № 3**
**к Краткосрочному плану реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Черемшанского муниципального района Республики Татарстан, в 2026 – 2028 годах**

**Реестр многоквартирных домов по видам ремонта, включенных в Краткосрочный план реализации региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Черемшанского муниципального района Республики Татарстан, в 2026-2028 годах**

| № п/п | Адрес многоквартирного дома | Стоимость капитального ремонта - всего | Виды, установленные ч.1 ст.166 Жилищного кодекса Российской Федерации | | | | | | | | | | разработка проектной документации на многоквартирные дома 2026 | разработка проектной документации на многоквартирные дома 2027 | разработка проектной документации на многоквартирные дома 2028 | осуществление строительного контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ремонт инженерных систем, в том числе: | | | | | | Ремонт фасада | | Ремонт крыши | | | | | |
| | | | Ремонт подъезда | | ХВС | | Электроснабжение | | | | | | | | | |
| | | рублей | пог.м. | рублей | пог.м. | рублей | пог.м. | рублей | кв.метр | рублей | кв.метр | рублей | рублей | рублей | рублей | рублей |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| | | | | | | | | 2026 | | | | | | | | |
| 1. | с.Черемшан ул.Полевая д.5 (Кирпичный завод) | 10 557 078,84 | 350,00 | 1 843 517,00 | | | 100,00 | 930 127,00 | 250,00 | 5 064 736,70 | 140,00 | 2 273 644,17 | 244 469,97 | 0,00 | 0,00 | 200 584,00 |
| | | 10 557 078,84 | 350,00 | 1 843 517,00 | | | 100,00 | 930 127,00 | 250,00 | 5 064 736,70 | 140,00 | 2 273 644,17 | 244 469,97 | 0,00 | 0,00 | 200 584,00 |
| | | | | | | | | 2027 | | | | | | | | |
| 1. | с.Черемшан ул. Техническая д.30 | 10 557 078,84 | | | | | | | 380,00 | 3 559 667,27 | 400,00 | 6 654 792,94 | 0,00 | 142 034,63 | 0,00 | 200 584,00 |
| | | 10 557 078,84 | | | | | | | 380,00 | 3 559 667,27 | 400,00 | 6 654 792,94 | 0,00 | 142 034,63 | 0,00 | 200 584,00 |
| | | | | | | | | 2028 | | | | | | | | |
| 1. | с.Кутема ул.Южная д.17 | 1 017 622,00 | | | 160,00 | 950 760,00 | | | | | | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 66 862,00 |
| 2. | с.Черемшан ул.Советская д.45А | 9 539 456,84 | | | | | | | | | 500,00 | 9 405 734,84 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 133 722,00 |
| | | 10 557 078,84 | | | 160,00 | 950 760,00 | | | | | 500,00 | 9 405 734,84 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 200 584,00 |

**Приложение № 4**
**к Краткосрочному плану реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31.12.2013 № 1146 «Об утверждении Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан», в 2026 – 2028 годах (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан**
**от ________________ 2025 № ________________)**

**Перечень многоквартирных домов, включенных в Краткосрочный план реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31.12.2013 № 1146 «Об утверждении Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан», в 2026 – 2028 годах**

| № п/п | Адрес МКД | Год | | Материал стен | Количество этажей | Количество подъездов | Общая площадь МКД | Площадь помещений МКД, кв.метров | | Количество жителей, зарегистри-рованных в МКД на дату утверждения программы | Вид ремонта | Стоимость капитального ремонта, рублей | | | | | Удельная стоимость капитального ремонта 1 кв.метра общей площади МКД | Предельная стоимость капитального ремонта 1 кв.метра общей площади МКД | Плановая дата завершения работ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ввода в эксплуатацию | завершения последнего капитального ремонта | | | | | всего | в том числе жилых помещений, находящихся в собственности граждан | | | итого | в том числе: за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации | за счет бюджета субъекта, рублей | за счет средств местного бюджета | за счет средств собственников помещений в МКД | | | |
| | | | | | | | кв.м. | кв.м. | кв.м. | человек | | рублей | рублей | рублей | рублей | рублей | рублей/кв.м | рублей/кв.м | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| | | | | | | | | | | 2026 | | | | | | | | | |
| 1 | с.Черемшан ул.Полевая д.5 (Кирпичный завод) | 1993 | 2009 | кирпичные | 2 | 2 | 813,00 | 747,00 | 747,00 | 37 | ремонт фасада, внутридомовой инженерной системы электроснабжения, крыши, подъездов | 10 557 078,84 | 0,00 | 8 000 000,00 | 616 000,00 | 1 941 078,84 | 12 985,34 | 14 000,00 | 31.12.2026 |
| Итого по району | | | | | | | 813,00 | 747,00 | 747,00 | 37 | | 10 557 078,84 | 0,00 | 8 000 000,00 | 616 000,00 | 1 941 078,84 | 12 985,34 | 14 000,00 | 31.12.2026 |
| | | | | | | | | | | 2027 | | | | | | | | | |
| 1 | с.Черемшан ул.Техническая д.30 | 1987 | 2009 | кирпичные | 2 | 2 | 994,60 | 858,40 | 858,40 | 43 | ремонт фасада, крыши | 10 557 078,84 | 0,00 | 8 000 000,00 | 616 000,00 | 1 941 078,84 | 10 614,40 | 14 000,00 | 31.12.2027 |
| Итого по району | | | | | | | 994,60 | 858,40 | 858,40 | 43 | | 10 557 078,84 | 0,00 | 8 000 000,00 | 616 000,00 | 1 941 078,84 | 10 614,40 | 14 000,00 | 31.12.2027 |
| | | | | | | | | | | 2028 | | | | | | | | | |
| 1 | с.Кутема ул.Южная д.17 | | | | 1 | 1 | 1 230,40 | 0,00 | 0,00 | 16 | ремонт внутридомовой инженерной [illegible] | 1 298 302,00 | 0,00 | 1 045 151,00 | 60 984,00 | 192 167,00 | 1 055,19 | 14 000,00 | 31.12.2028 |
| 2 | с,Черемшан ул.Советская д.45А | 1982 | 2010 | кирпичные | 2 | 3 | 1 543,70 | 948,29 | 948,29 | 48 | ремонт крыши | 9 258 776,84 | 0,00 | 6 954 849,00 | 555 016,00 | 1 748 911,84 | 5 997,78 | 14 000,00 | 31.12.2028 |
| Итого по району | | | | | | | 2 774,10 | 0,00 | 0,00 | 64 | | 10 557 078,84 | 0,00 | 8 000 000,00 | 616 000,00 | 1 941 078,84 | 7 052,97 | 14 000,00 | 31.12.2028 |